Республика Татарстан
ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**2024 ел 21 март** **№ 3**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 № 1, «Ләке торак пунктында гражданнарның 2024 елда үзара салым кертү турында»17.11.2023 № 2 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1.2024 елның 30 мартында 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Ләке авылы, Тау башы урамы, 12 а йорт адресы буенча урнашкан Ләке авыл мәдәният йорты бинасында "Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында»17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 17.11.2023 №1, «Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында» 17.11.2023 №2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы?
1)Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
2. Ләке торак пункты территориясен җәй көне юл кырыйларын чабып, чистартып тору (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), бензочапкыч һәм

Беларусь МТЗ 82.1 өчен ягулык-майлау материаллары; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу);
3. Ләке торак пунктыда традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм койма кую эшләре өчен түләү);
4. Ләке торак пунктыда электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка бүлү пунктларын һәм башка мәйданчыкларны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (яктыртуның урам челтәрләрен ремонтлау (лампаларны, таймерларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру).
5. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Ләке торак пунктында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү).

6. Ләке торак пунктыда Коеларны ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

«ӘЙЕ «ЮК»

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Ю.Г.Антонов